| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| « 29 » 11 2024 ел | № 26 |

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә кергән гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 04 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитеты 08.10.2015нче елның 22 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Кече Лызи» муниципаль берәмлегенә кергән гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау Тәртибе» нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 1.2 пунктында «электрон хәбәрләр рәвешендә» сүзләреннән соң «электрон документ рәвешендә, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып,» сүзләрен (алга таба - Бердәм портал),» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Кече Лызи авыл жирлеге бүлегендә (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы — А.С.Исмагилов